ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.02.2022 ел Баулы шәһәре №25

Баулы муниципаль районы бюджетыннан
автомобиль транспортында шәһәр һәм
шәһәр яны юлларында муниципаль маршрутлар
буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне
һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик
затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның
Татарстан Республикасында яңа коронавирус
инфекциясе таралуны булдырмау максатларында
чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә алынмый
калган керемнәрен каплауга субсидияләр бирү
тәртибен, нигезләмәсен һәм комиссия составын
раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 нче маддәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр бирүне, шул исәптән юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында, һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында шәһәр һәм (яисә) шәһәр яны юлларында муниципаль маршрутлар буенча, метрополитенда даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатларында чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә алынмый калган керемнәрен каплау максатларында Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бүлүне раслау турында” 2022 елның 7 февралендәге 173-р номерлы

күрсәтмәсе Нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

- Шәһәр һәм шәһәр яны юлларында муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатларында чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә алынмаган керемнәрен каплауга Баулы муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе (1 нче кушымта);

- Шәһәр һәм шәһәр яны юлларында муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатларында чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә алынмаган керемнәрен каплауга хокуклыларны сайлап алу комиссиясе турында нигезләмә (2 нче кушымта);

- Шәһәр һәм шәһәр яны юлларында муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатларында чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә алынмаган керемнәрен каплауга хокуклыларны сайлап алу комиссиясе составы (3 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров